«Тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе
«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе

# УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ӨЙРӘНӘБЕЗ

Методик тәкъдимнәр җыентыгы

Казан
Фолиант
2019

УДК 373.21
ББК 74.100.5
У37

«Тормыш иминлеге фәнни үзәге»
дәүләт бюджет учреждениесе
Гыйльми советы тәкъдиме белән нәшер ителде

*Рецензентлар*:
педагогика фәннәре докторы, профессор, КФУның
психология һәм мәгариф Институтының мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү
кафедрасы җитәкчесе *В.Г. Закирова;*
Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының мәктәпкәчә белем
бирү лабораториясе мөдире *Г.Х. Манюрова*

*Автор-төзүчеләр:*
Казан шәһәре Вахитов районының 24 нче катнаш төрдәге татар телендә тәрбия
һәм белем бирүче балалар бакчасы мөдире *Мәрдәнова Айгөл Әбделгани кызы*,
тәрбиячеләр *Таипова Гөлназ Камил кызы*, *Зарипова Гөлназ Исмәгыйль кызы,*
*Вәлиева Гөлнара Зәнфир кызы, Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы,*
*Баһаветдинова Илсөя Зөфәр кызы.*

У37 **Уйный-уйный өйрәнәбез: методик тәкъдимнәр җыентыгы** / Авт.-төз.: А.Ә. Мәрдәнова, Г.К. Таипова, Г.И. Зарипова, Г.З. Вәлиева, Л.Ф. Шәрәфиева, И.З. Баһаветдинова. – Казан: Фолиант, 2019. – 48 б.

«Уйный-уйный өйрәнәбез» методик тәкъдимнәр җыентыгы балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм ата-аналар өчен әзерләнелде. Кулланмада, балаларны юлларда үз иминлекләрен саклау күнекмәләренә өйрәтү өчен, кызыклы уеннар тупланды. Мавыктыргыч уеннар балаларның юл хәрәкәте әлифбасын өйрәнүгә кызыксынуларын арттырырга булышыр.

Әлеге методик тәкъдимнәр җыентыгы Казан шәһәренең татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 24 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы тәрбиячеләре эш тәҗрибәсенә нигезләнеп төзелде.

ISBN
0+

© «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» ДБУ, 2019
© «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ 2019
© Фолиант, 2019.

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ ........ 4

БАЛАЛАРНЫ ЮЛЛАРДА ҮЗ ИМИНЛЕКЛӘРЕН САКЛАУ КҮНЕКМӘЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮ УЕННАРЫНЫҢ ПЕРСПЕКТИВ ПЛАНЫ ........ 9

Кечкенәләр төркемнәрендә юлларда тормыш иминлеге кагыйдәләрен өйрәтү өчен уеннар (3–4 яшьлек балалар өчен) ........ 12

Уртанчылар төркемендә юлларда тормыш иминлеге кагыйдәләрен өйрәтү өчен уеннар (4–5 яшьлек балалар өчен) ........ 19

Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә юлларда тормыш иминлеге кагыйдәләрен өйрәтү өчен уеннар (5–7 яшьлек балалар өчен) ........ 32

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ ........ 43

# КЕРЕШ

Без барыбыз да юлларда җәяүле ролен башкарабыз. Сәламәтлегебез, хәтта тормышыбыз үзебезне юлларда дөрес тоту-тотмау белән турыдан-туры бәйле. Юл һәлакәтләрнең күпчелеге мәктәпкәчә яшьтәге балалар катнашында килеп чыга. Моның сәбәпләре төрле булырга мөмкин: ата-аналарның игътибарсызлыгы, балаларның үз-үзен тотышы, балалар белән тиешле сөйләшүләр, әңгәмәләр алып барылмау, юл йөрү кагыйдәләре белән тиешле дәрәҗәдә таныш булмау, ата-аналарның юл йөрү кагыйдәләрен үтәмәүләре һ. б.

Мондый хәвеф-хәтәрләрне булдырмас өчен, ата-аналар белән белем бирү оешмаларының хәбәрләшеп эшләве, барлык эшчәнлек төрләрен һәм ФДББС билгеләгән биш белем бирү өлкәсен дә исәпкә алып, системалы һәм эзлекле эш алып баруы кирәк.

**Хезмәтнең максаты** – мәктәпкәчә яшьтәге балаларның юл хәрәкәте кагыйдәләрен төрле ситуациядә куллана белү өлкәсендә белемнәрен үстерү.

**Бурычлары:**

– юл йөрү кагыйдәләре турында беренчел күзаллаулар формалаштыру;

– юл йөрү кагыйдәләрен җәяүле буларак үтәү күнекмәләрен үстерү;

– юлда, маршрут транспорт чараларында, велосипедта йөргәндә үз-үзеңне дөрес тоту культурасын тәрбияләү.

## «Танып-белү үсеше» белем бирү өлкәсендә балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү

Танып белү үсеше баланың кызыксынучанлыгы, хыялы һәм иҗади активлыгы үсешен, әйләнә-тирә дөнья, шул исәптән юл хәрәкәте кагыйдәләре турындагы беренчел белемнәре формалашуын күз алдында тота.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны «Танып-белү үсеше» аша, юл йөрү кагыйдәләре белән таныштырыр өчен, түбәндәге бурычлар куела:

– юл хәрәкәте кагыйдәләре турында беренчел күзаллау формалаштыру;

– җәяүлеләргә һәм транспорт йөртүчеләргә карата сакчыл караш һәм хөрмәт тәрбияләү.

Юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү барышында мөһим моментларның берсе булып, балаларда кызыксынучанлык, иҗади активлык кебек сыйфатларны тәрбияләү тора. Алар мәктәпкәчә белем бирү ФДББСның максат ориентирлары буларак тәкъдим ителә.

Юл йөрү кагыйдәләренә өйрәткәндә танып-белүнең актив методларын һәм алымнарын (күзәтү, дидактик уеннар, экскурсияләр һ. б.) куллану отышлы.

«Танып-белү үсеше» өлкәсендә белемнәр формалаштыру өчен, эзләнү-тикшеренү эшчәнлеге уңышлы санала. Әлеге эшчәнлек белемнәрне тормышта кулланырга, ягъни теоретик белемнәрне практика ярдәмендә ныгытырга булыша.

**Методлар:**

– проблемалы ситуацияләрне чишү;
– модельләштерү;
– дидактик уеннар;
– интеллектуаль уеннар;
– хәрәкәтле уеннар.

### «Социаль-коммуникатив үсеш» белем бирү өлкәсе аша балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү

Социаль-коммуникатив үсеш җәмгыятьтә кабул ителгән нормаларны һәм кыйммәтләрне үзләштерүгә, көнкүрештә, социумда, табигатьтә үз-үзеңне имин тоту нигезләрен булдыруга юнәлтелгән.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары ФДББСның максат ориентирлары нигезендә, баланың яшьтәшләре һәм олылар белән актив аралашу, башкаларның хис-кичерешләрен һәм кызыксынуларын исәпкә алу, башкалар белән бергә сөенә һәм борчыла белү, уен процессында актив катнашу кебек сыйфатларга ия булырга тиешлеге билгеләнелә.

Юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү уңышлы һәм нәтиҗәле булсын өчен уен эшчәнлеген куллану урынлы. Юлларда үзеңне дөрес тоту күнекмәләре һәм мораль нормалары уен эшчәнлеге процессында тизрәк формалаша. Педагогик яктан дөрес оештырылган уен ярдәмендә балаларның активлыгына, бирелгән биремнәрне кызыксынып эшләүләренә һәм мәгълүматны җиңелрәк үзләштерүләренә ирешергә мөмкин.

Уеннарны оештырганда балаларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләре исәпкә алынырга тиеш. Эшчәнлек барышында балаларның мөстәкыйль фикерләүләренә, бирелгән сорауларга җавап табуларына ирешү мөһим. Ребуслар, кроссвордлар чишү балаларның интеллектуаль үсешен камилләштерергә ярдәм итә.

**Методлар:**

– әңгәмә, сөйләшү;
– табышмаклар чишү;

– уен ситуациясе булдыру;
– дидактик уеннар;
– интеллектуаль уеннар.

### «Сөйләм үстерү» белем бирү өлкәсе аша балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү

Сөйләм үсеше, аралашу һәм мәдәният чарасы буларак, актив сөйләмгә ия булуны, сүзлек байлыгын үстерүне, китап культурасы, балалар әдәбияты белән танышуны үз эченә ала.

Әлеге белем бирү өлкәсе аша юл йөрү кагыйдәләренә өйрәткәндә, балаларның актив сүзлеген юл, юл билгеләренә караган терминнар белән баету күз уңаенда тотыла. Көндәлек тормышта без һәрвакыт аралашып, фикер алышып торабыз. Уен эшчәнлеген дә сөйләмсез, аралашусыз күз алдына китереп булмый. Дөрес методлар кулланган очракта гына уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

**Методлар:**
– матур әдәбият уку, фикер алышу;
– яттан сөйләү;
– әңгәмәләр үткәрү;
– сораулар һәм җаваплар;
– рәсемнәр һәм иллюстрацияләр карау;
– экскурсияләр үткәрү;
– проблемалы укыту;
– дидактик уеннар.

### «Сәнгати-эстетик» белем бирү өлкәсе аша балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү

Сәнгати-эстетик үсеш сәнгать әсәрләрен, табигать дөньясын кыйммәт-мәгънә ягыннан кабул итү һәм аңлау алшартлары үсешен, сәнгать төрләре турында элементар күзаллаулар формалашуын күздә тота.

Татар телендә белем һәм тәрбия бирүче 24 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы участогында, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү һәм ныгыту өчен, барлык шартлар да тудырылган. Балалар бакчасының ишегалды чын шәһәр урамы кебек ясалган. Биредә олы юл, җәяүлеләр юлы, «зебра» тибындагы сызык белән җәяүлеләр өчен кичү, светофорлар, юл йөрү билгеләре бар. Балалар юл йөрү кагыйдәләрен саф һавада даими рәвештә кабатлап, белемнәрен ныгытып торалар.

**Методлар:**
- күмәк һәм индивидуаль эшчәнлек;
- музыкаль күнегүләр;
- күрсәтмәлелек;
- бәйрәмнәр һәм чаралар оештыру;
- рәсемнәр һәм иллюстрацияләр карау;
- матур әдәбият әсәрләре белән танышу;
- театральләштерелгән уеннар;
- музыкаль-дидактик уеннар.

**«Физик үсеш» белем бирү өлкәсе аша балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү**

Физик үсеш хәрәкәтләнү, организмның терәк-хәрәкәт системасын дөрес формалаштыру, тигезлек саклау, хәрәкәтне координацияләү, спортның кайбер төрләре турында башлангыч күзаллаулар формалаштыруны үз эченә ала.

«Физик үсеш» белем бирү өлкәсе кысаларында да, балаларның юл хәрәкәте кагыйдәләре турында белем һәм күнекмәләрен формалаштыру юнәлешендә эш алып барырга мөмкин. Эш барышында урамны күзәтергә, ишегалдында урнаштырылган юл билгеләренә туры килгән биремнәр эшләргә, юл йөрү кагыйдәләрен үтәүнең сәламәтлеккә турыдан-туры бәйле булуы хакында кыска әңгәмәләр үткәрергә мөмкин.

**Методлар:**
- әңгәмәләр үткәрү;
- күнегүләр барышына музыка әсәрләрен куллану;
- үзара ярышлар оештыру;
- хәрәкәтле уеннар;
- спорт уеннары.

Әлеге методик тәкъдимнәрдә китерелгән уеннар белем бирү өлкәләре эчтәлегенә туры киләләр, ягъни, уеннар, юл хәрәкәте кагыйдәләрен ФДББС нигезендә өйрәтергә җирлек булып тора алалар.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәр формалаштыру өчен, белем бирү оешмасы кысаларыннан тыш та эшчәнлек алып барырга кирәк. Китапханәләргә бару, экскурсияләр оештыру, юл йөрү кагыйдәләренә багышланган бәйгеләрдә катнашу, әлеге темага төрле чаралар оештыру уңышлы алымнардан санала.

Балаларның юлларда үзеңне дөрес тоту турында күзаллауларын формалаштыру максатыннан, ЮХИДИ инспекторлары белән очрашулар

үткәрергә мөмкин. ЮХИДИ хезмәткәрләре катнашында оештырылган акцияләр, викториналар балалар өчен аеруча кызыклы һәм файдалы.

Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрне формалаштыру һәм ныгыту эшчәнлегенә ата-аналарны җәлеп итү, алар белән хәбәрләшеп эшләү мөһим. Балалар ата-аналардан үрнәк ала, аларга охшарга тырыша. Шуңа күрә ата-аналар үзләре бу кагыйдәләрне үтәргә, әлеге темага әңгәмәләр үткәрергә, балаларына уңай үрнәк күрсәтергә тиешләр. Шундый күмәк эшчәнлек бала һәм зурлар арасында эмоциональ, психологик уңай халәт тудыра; балага үзен «зурларча» тоярга, ә зурларга балаларны яхшырак аңларга мөмкинлек бирә.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга нинди дә булса мәгълүматны тапшыруның иң нәтиҗәле юлы – уеннар куллану. Уеннар баланың шәхес булып формалашуына зур йогынты ясый, психик үсешенә, сөйләм эшчәнлеген камилләштерүгә, үзенең сәләтләрен күрсәтергә ярдәм итә. Уен тәрбиячегә баланы, аның холкын тагын да яхшырак аңларга, аның сәләтен ачарга булыша.

Безнең бакчабыз тәрбиячеләре, әлеге факторларны исәпкә алып, юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнгәндә кулланырга мөмкин булган уеннар тупланган махсус җыентык эшләделәр. Тәкъдим ителгән уеннар мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсеш үзенчәлекләрен искә алып төзелде.

Әлеге методик тәкъдимнәр җыентыгында китерелгән уеннар мәктәпкәчә яшьтәге балаларда юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрне формалаштыруда, юлда игътибарлы һәм сак булуны өйрәтүдә ярдәм итәр дип өметләнәбез.

## БАЛАЛАРНЫ ЮЛЛАРДА ҮЗ ИМИНЛЕКЛӘРЕН САКЛАУ КҮНЕКМӘЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮ УЕННАРЫНЫҢ ПЕРСПЕКТИВ ПЛАНЫ

### Кечкенәләр төркеме

| № | Уеннар исеме | Бурычлар |
|---|---|---|
| 1. | «Мәче һәм тычкан» | Балаларда игътибарлылык тәрбияләү, светофор сигналы төсләрен танырга өйрәтү. |
| 2. | «Светофор» | Балаларда игътибарлылык, җитезлек тәрбияләү, светофор сигналы төсләрен аеру күнекмәләрен ныгыту. |
| 3. | «Үз флагчыгыңны тап» | Балаларда җитезлек тәрбияләү, әйләнә-тирәдә ориентлашу һәм светофор сигналы төсләрен тану күнекмәләрен ныгыту. |
| 4. | «Төсле кәрзиннәр» | Светофор сигналы төсләрен аеру күнекмәләрен үстерү, игътибарлылык, җитезлек тәрбияләү. |
| 5. | «Поезд» | Светофор сигналы төсләрен танырга өйрәтү, төсләрне аеру күнекмәләрен ныгыту, игътибарлылык тәрбияләү. |
| 6. | «Светофор» | Төсләрне аеру, светофор сигналы төсләренең эзлеклелеген тану күнекмәләрен ныгыту, игътибарлылык тәрбияләү. |
| 7. | «Төсле фигуралар» | Светофор сигналы төсләре һәм фигуралар турындагы белемнәрен ныгыту, предметларны төркемли алу күнекмәләрен үстерү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| 8. | «Автомобильне гаражга керт» | Балаларның светофор сигналы төсләрен һәм транспорт чараларының төрләрен аера белү күнекмәләрен ныгыту, игътибарлылык тәрбияләү. |
| 9. | «Транспорт чаралары» | Балаларның сүзлек запасын баету, транспорт чараларының төрләре хакында белемнәрен ныгыту, игътибарлылык тәрбияләү. |
| 10. | «Зур һәм кечкенә» | Балаларның транспорт чараларының төрләре турындагы белемнәрен ныгыту, предметларны зурлыклары буенча чагыштырырга һәм аерырга өйрәтү. |
| 11. | «Рәсемне җый» | Балаларның транспорт чараларының төрләре турындагы белемнәрен, игътибарлылыкларын, берничә өлештән торган рәсемне җыя белү сәләтләрен үстерү. |

## Уртанчылар төркеме

| № | Уен исеме | Бурычлар |
|---|---|---|
| 1. | «Саннар илендә» | Балаларның саннар турындагы белемнәрен ныгыту, транспорт чараларының төрләрен кабатлау. |
| 2. | «Транспорт чаралары төрләре» | Балаларның игътибарлылыкларын үстерү, транспорт чараларының төрләре турындагы белемнәрен ныгыту. |
| 3. | «Һава транспорт чараларын тап!» | Балаларның транспорт чараларының төрләрен аера белү күнекмәләрен ныгыту, игътибарлылыкларын үстерү. |
| 4. | «Махсус транс-порт чаралары төрләрен бел!» | Балаларны махсус транспорт чараларының төрләре белән таныштыру, исемнәрен истә калдыруларына ирешү. |
| 5. | «Сүзне тап» | Балаларның транспорт чараларының төрләре турындагы белемнәрен ныгыту, сөйләм телен үстерү. |
| 6. | «Кайсы артык?» | Балаларның транспорт чаралары турындагы белемнәрен ныгыту һәм аларны дөрес итеп аерырга өйрәтү. |
| 7. | «Светофор» | Балаларның сөйләм телен үстерү; светофор төшенчәсе, төсләр турындагы белемнәрен ныгыту. |
| 8. | «Серле фигуралар» | Балаларның юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча белемнәрен ныгыту, геометрик фигураларны кабатлау. |
| 9. | «Шаян фигуралар» | Балаларның транспорт чараларының төрләре һәм геометрик фигуралар турындагы белемнәрен киңәйтү, санау тәртибен искә төшерү. |
| 10. | «Велосипед йөртүчене дөрес итеп киендер» | Балаларга велосипед йөртүченең махсус киеме барлыгын өйрәтү, әлеге киемнең велосипед йөртүченең гомерен һәм сәламәтлеген сакларга булышуын аңлату. |
| 11. | «Дөресме, ялгышмы?» | Балаларның игътибарлылыкларын, сөйләм телен үстерү, юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча белемнәрен ныгыту. |
| 12. | «Сөйләүче юл билгеләре» | Балаларның образлы фикерләү сәләтен, юл билгеләре турындагы белемнәрен, игътибарлылыкларын үстерү. |
| 13. | «Юл билгеләре» | Балаларның юл билгеләре турындагы белемнәрен киңәйтү, сөйләм телен үстерү. |

## Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме

| № | Уен исеме | Бурычлар |
|---|---|---|
| 1. | «Сүзне укы!» | Балаларның юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча белемнәрен ныгыту, игътибарлылыгын, уку күнекмәләрен үстерү. |
| 2. | «Сихерләнгән сүзләр» | Балаларның игътибарлылыгын, тиз фикер йөртә белү сәләтләрен үстерү. |
| 3. | «Һәр хәрефнең яңа «өен» тап!» | Балаларның юл хәрәкәте терминнары турындагы белемнәрен ныгыту, тиз фикер йөртә белү сәләтләрен үстерү, уку күнекмәләрен камилләштерү. |
| 4. | «Яшерелгән сүзләр» Кроссворд: «Транспорт чаралары», «Светофор» | Балаларның сүзлек запасын юл хәрәкәтенә кагылышлы терминнар белән баету, игътибарлылыкларын үстерү, уку күнекмәләрен ныгыту. |
| 5. | «Автомобильләрнең маркалары» | Балаларның автомобильләр маркаларын таный алуларына ирешү; балаларның фикерләү сәләтләрен, сүзгә аваз анализы ясау күнекмәләрен үстерү. |
| 6. | «Юлдан барабыз» | Балаларның юл билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту; сөйләм сулышын үстерү: Р; Ш; С; Л авазларының дөрес әйтелешен ныгыту. |
| 7. | «Кайсы артык?» | Төркемли белү күнекмәләрен, гомумиләштерүче сүзләрне һәм логик фикерләүне, сүз байлыгын, игътибарлылыкны үстерү. |
| 8. | «Нәрсә яшерелгән?» | Балаларның игътибарлылыгын үстерү, хәтер күләмен арттыру. |
| 9. | «Охшаган, охшамаган?» | Балаларның игътибарлылыгын үстерү, юл билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту. |
| 10. | «Нәрсә югалды?» | Балаларның игътибарлылыгын, хәтер күләмен, тиз фикер йөртү сәләтләрен үстерү. |
| 11. | «Нинди билге?» | Балаларның юл билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту; тиз фикер йөртә белү сәләтләрен, ситуацияне аңлап, фикерләрен дөрес итеп җиткерә белү күнекмәләрен үстерү. |
| 12. | «Хатаны тап» | Балаларның юлда йөрү иминлек кагыйдәләре турындагы белемнәрен ныгыту, сөйләмнәрен үстерү; юлдагы ситуацияне дөрес бәяли белергә өйрәтү. |

## Кечкенәләр төркемнәрендә юлларда тормыш иминлеге кагыйдәләрен өйрәтү өчен уеннар (3–4 яшьлек балалар өчен)

### *«Мәче һәм тычкан» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Таипова Гөлназ Камил кызы.

***Бурычлар:*** балаларда игътибарлылык тәрбияләү, светофор сигналларын танырга өйрәтү.

***Уен барышы.*** Бер бала (яки тәрбияче үзе) – мәче, калганнары тычканнар булып билгеләнәләр. «Мәче» светофор сигналы төсләрен әйтә: яшел – «тычканнар» төрле яккка йөгерешәләр, сары – бер урында сикерәләр, кызыл – туктап калалар. Командаларны дөрес үтәмәгән балаларны «мәче» тота һәм алар уеннан чыгалар.

### *«Светофор» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Таипова Гөлназ Камил кызы.

***Бурычлар:*** балаларда игътибарлылык, җитезлек тәрбияләү, светофор сигналы төсләрен аеру күнекмәләрен ныгыту.

***Материал:*** төсле катыргыдан ясалган кызыл, яшел түгәрәкләр, җирдә түгәрәк ясау өчен акбурлар.

***Уен барышы.*** Уен урамда җәй көне уйнала. Җиргә кызыл, сары, яшел түгәрәкләр сызыла. Балаларның кулларына төсле катыргыдан ясалган кызыл, сары, яшел түгәрәкләр бирелә. Тәрбияче: «Бер, ике, өч – түгәрәккә йөгер!» – дигәч, балалар кулларындагы түгәрәк төсендәге түгәрәк эченә басарга тиеш була.

### *«Үз флагчыгыңны тап» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Таипова Гөлназ Камил кызы.

***Бурычлар:*** балаларда җитезлек тәрбияләү, әйләнә-тирәдә ориентлашу һәм светофор сигналы төсләрен тану күнекмәләрен ныгыту.

***Материал:*** кызыл, сары, яшел флагчыклар.

***Уен барышы.*** Уйнаучылар өч төркемгә бүленәләр һәм, кулга-кул тотынып, түгәрәк ясап басалар, ә уртада кызыл, сары яки яшел флагчык тоткан бала тора. Һәр түгәрәк уртасында торучы баланың кулында бер генә (һәр төркемнеке төрле төстә) флагчык. Тәрбияче сигналы буенча, флаг тоткан балалардан башкалары төрле якка йөгерешәләр. Икенче сигналдан соң, балалар туктыйлар, чүгәлиләр һәм күзләрен йомалар. Бу вакытта флагчык тоткан балалар урыннарын алмаштыралар. «Үз флагчыгыңа йөгер!» командасы яңгырагач, уйнаучылар күзләрен ачарга һәм үз флагчылары-

на таба йөгерергә тиеш була. Иң беренче булып җыелып беткән команда җиңүче була.

### *«Төсле кәрзиннәр» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Таипова Гөлназ Камил кызы.

***Бурычлар:*** светофор сигналы төсләрен аеру күнекмәләрен үстерү, игътибарлылык, җитезлек тәрбияләү.

***Материал:*** кызыл, сары, яшел төстәге кәрзиннәр, туплар.

***Уен барышы.*** Уйнаучылардан 3–4 адым ераклыкта кызыл, сары, яшел төстәге кәрзиннәр куела. Алып баручы кәрзин төсләрен атый, балалар тупларны дөрес кәрзингә салырга тиеш була.

### *«Поезд» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Таипова Гөлназ Камил кызы.


***Бурычлар:*** светофор сигналы төсләрен танырга өйрәтү, төсләрне аеру күнекмәләрен ныгыту, игътибарлылык тәрбияләү.

***Материал:*** кызыл, сары, яшел флагчыклар.

***Уен барышы.*** Балалар, бер-бер артлы тезелеп, колоннага басалар. Кулына кызыл, сары, яшел төстәге флагчыклар тоткан алып баручы яшел флагчыкны күтәргәч, «поезд» кузгала, сары флагчыкны күтәргәч, балалар бер урында таптанып торалар, кызыл флагчык күтәргәч туктыйлар.

### *«Светофор» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Таипова Гөлназ Камил кызы.



***Бурычлар*:** төсләрне аеру, светофор сигналы төсләренең эзлеклелеген тану күнекмәләрен ныгыту, игътибарлылык тәрбияләү.

***Материал:*** проектор, ноутбук.

***Уен барышы.*** Экранда светофор сигналы төсләрендәге түгәрәкләр һәм светофор макеты рәсеме күрсәтелә. Балалар түгәрәкләрнең төсләрен әйтәләр, соңыннан түгәрәк төсләрен светофор сигналы эзлеклелегендә атыйлар. Балалар төсләрне дөрес атаган саен, түгәрәкләр светофор макетына урнаша баралар.


**_«Төсле фигуралар» уены_**

***Уенның авторы*** – тәрбияче Таипова Гөлназ Камил кызы.

***Бурычлар:*** балаларның светофор сигналлары һәм геометрик фигуралар турындагы белемнәрен ныгыту, предметларны төркемли алу күнекмәләрен үстерү, игътибарлылык тәрбияләү.

***Материал:*** кызыл, сары, яшел төсләрдәге геометрик фигуралар һәм шундый ук төстәге савытлар.

***Уен барышы.*** Балаларга светофор сигналы төсендәге геометрик фигуралар өләшенә. Өстәлгә кызыл, сары, яшел төстәге савытлар куела һәм балалар фигураларны үз төсенә туры килгән савытларга салырга тиеш була. Фигураларны кирәкле савытларга урнаштырып бетергәч, аларның төсләренә игътибар иттерелә. Уен ахырында балалар савытларны светофор сигналының төсләре эзлеклелегендә урнаштырырга тиеш.



**«Автомобильне гаражга керт» уены**

***Уенның авторы*** – тәрбияче Таипова Гөлназ Камил кызы.


***Бурычлар:*** балаларның төсләрне һәм транспорт чаралары төрләрен аера белү күнекмәләрен ныгыту, игътибарлылык тәрбияләү.

***Материал:*** төсле катыргыдан ясалган өй макетлары, уенчык автомобильләр.

***Уен барышы.*** Балаларга автомобильләрне үз төсләрендәге гаражга кертергә кирәклеге аңлатыла. Уен барышында түбәндәге сорауларга нигезләнеп эшләргә мөмкин:

- Автомобиль нинди төстә? – Яшел.
- Бу гараж нинди төстә ? – Сары.
- Автомобильне бу гаражга кертә алабызмы? – Юк, чөнки алар бер төстә түгел!

Уен автомобиль төсенә туры килгән гаражга кадәр дәвам итә.




***«Транспорт чаралары» уены***


***Уенның авторы*** – тәрбияче Таипова Гөлназ Камил кызы.

***Бурычлар:*** балаларның сүзлек запасын баету, транспорт чаралары төрләре хакында белемнәрен ныгыту, игътибарлылык тәрбияләү.

***Материал:*** җир һәм һава транспорты чаралары ясалган рәсемнәр.

***Уен барышы.*** Балаларга җир һәм һава транспорты чаралары ясалган рәсемнәр тәкъдим ителә. Балалар транспорт чаралары атамаларын әйтергә һәм аларны ике төркемгә (җир һәм һава транспорт чараларына) бүлеп куярга тиеш.




















### *«Зур һәм кечкенә» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Вәлиева Гөлнара Зәнфир кызы.

***Бурычлар:*** балаларның транспорт чаралары төрләре турындагы белемнәрен ныгыту, предметларны зурлыклары буенча чагыштырырга һәм аерырга өйрәтү.

***Материал:*** транспорт чаралары ясалган рәсемнәр.

***Уен барышы.*** Балаларга төрле транспорт чаралары ясалган рәсемнәр таратыла. Рәсемнәрдәге транспорт чаралары төрле зурлыкта булуы мөһим. Балалар кайсы транспорт чаралары төре сурәтләнгәнен атарга һәм аларның кайсы зур, кайсы кечкенә икәнен билгеләргә тиеш.




### *«Рәсемне җый» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Вәлиева Гөлнара Зәнфир кызы.

***Бурычлар:*** балаларның транспорт чаралары төрләре турындагы белемнәрен, игътибарлылыкларын, берничә өлештән торган рәсемне җыя белү сәләтләрен үстерү.

***Материал:*** транспорт чаралары төрләре ясалган һәм берничә кисәккә киселгән рәсемнәр.

***Уен барышы.*** Балаларга транспорт чаралары төрләре ясалган һәм берничә кисәккә бүленгән рәсемнәр таратыла. Алар кисәкләрдән тулы рәсемне җыярга тиеш. Балалар җыелган рәсемнәрдәге транспорт чаралары төрләренең атамаларын әйтәләр.



## Уртанчылар төркемендә юлларда тормыш иминлеге кагыйдәләрен өйрәтү өчен уеннар (4–5 яшьлек балалар өчен)


### *«Саннар илендә» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Вәлиева Гөлнара Зәнфир кызы.

***Бурычлар:*** балаларның саннар турында белемнәрен ныгыту, транспорт чаралары төрләрен кабатлау.

***Материал:*** транспорт чаралары һәм саннар ясалган рәсемнәр.

***Уен барышы.*** Балаларга транспорт чаралары төрләре һәм аларның асларына саннар төшерелгән карточкалар таратыла. Балалар рәсемнәрдә нинди транспорт чаралары төре сурәтләнгәнен атыйлар, аларның ничә данә булуын саныйлар һәм транспорт чаралары санына туры килгән цифрны түгәрәк эченә алалар.



| | | |
|---|---|---|
| 2 3 5 | 1 2 3 | 5 4 6 |

***«Транспорт чаралары төрләре» уены***

***Уенның авторы*** **–** тәрбияче Зарипова Гөлназ Исмәгыйль кызы.

***Бурычлар:*** балаларның игътибарлылыкларын үстерү, транспорт чаралары турындагы белемнәрен ныгыту.

***Материал:*** транспорт чаралары сурәтләнгән карточкалар, транспорт чараларының макетлары.

***Уен барышы.*** Балалар ике командага бүленә. Беренче команда – «Җир транспорты», икенче команда «Һава транспорты» була. Өстәлгә төрле транспорт чаралары төшерелгән карточкалар куела. Командалар үз исемнәренә туры килгән транспорт чараларын табарга (җир транспорты, һава транспорты) һәм аларның нинди вазыйфа үтәгәннәрен аңлатып бирергә тиеш. Күбрәк дөрес җавап биргән команда җиңүче була.



***«Һава транспорты чараларын тап!» уены***

***Уенның авторы*** – тәрбияче Вәлиева Гөлнара Зәнфир кызы.

***Бурычлар:*** балаларның транспорт чаралары төрләрен аера белү күнекмәләрен ныгыту, игътибарлылыкларын үстерү.

***Материал:*** транспорт чаралары ясалган рәсемнәр.

***Уен барышы.*** Балаларга җир һәм һава транспорты чаралары төрләре төшерелгән рәсемнәр таратыла. Балалар рәсемнәрдән һава транспорты чараларын табарга һәм атамаларын дөрес итеп әйтергә тиеш.



***«Махсус транспорт чаралары төрләрен бел!» уены***

***Уенның авторы*** – тәрбияче Вәлиева Гөлнара Зәнфир кызы.

***Бурычлар:*** балаларны махсус транспорт чаралары белән таныштыру, исемнәрен истә калдыруларына ирешү.

***Материал:*** махсус транспорт чаралары ясалган рәсемнәр.

***Уен барышы.*** Балаларга махсус транспорт чаралары ясалган рәсемнәр күрсәтелә һәм аларның атамалары әйттерелә. Педагог балаларга түбәндәге сорауларны бирә:

1. Кайсы транспорт чарасында авыруларга ярдәмгә ашыгалар?
2. Кайсы транспорт чарасы белән янгынны сүндерәләр?
3. Кайсы транспорт чарасы белән юллардагы асфальтны тигезлиләр?
4. Кайсы транспорт чарасында юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәү сагында торалар?
5. Газ чыкканда, кайсы транспорт чарасында киләләр?
6. Авыр йөкләрне нинди транспорт чарасы белән күтәрәләр?

Балалар сорауны игътибар белән тыңларга һәм әлеге тасвирламага туры килгән транспортның рәсемен эзләп табарга тиешләр. Барлык сорауларга җаваплар тапканнан соң, балалар махсус транспорт чаралары ясалган рәсемнәрне башка рәсемнәрдән аерып куялар.



***«Сүзне тап» уены***

***Уенның авторы*** – тәрбияче Зарипова Гөлназ Исмәгыйль кызы.

***Бурычлар:*** балаларның транспорт чаралары турындагы белемнәрен ныгыту, сөйләм телен үстерү.

***Материал:*** төрле предметлар төшерелгән карточкалар, транспорт чараларының макетлары.

***Уен барышы.*** Тәрбияче балаларга рәсемнәр төшерелгән карточкалар тарата. Карточкалар буталган. Балалар төрле предметлар ясалган әлеге сурәтләр арасыннан транспорт чарасы рәсемен табарга һәм аның кайсы төргә туры килгәнен, нинди вазыйфа башкарганын да әйтеп бирергә тиешләр.




***«Кайсы артык?» уены***

***Уенның авторы*** – тәрбияче Зарипова Гөлназ Исмәгыйль кызы.

***Бурычлар:*** балаларның транспорт чаралары турындагы белемнәрен ныгыту һәм аларны дөрес итеп аерырга өйрәтү.

***Материал:*** транспорт чараларының макетлары, проектор.

***Уен барышы.*** Тәрбияче уен башында балаларга транспорт чаралары төшерелгән карточкалар өләшә һәм балалар белән карточкалар ярдәмендә транспорт чараларының төрләрен һәм аларның нинди вазыйфа башкарганнарын кабатлыйлар. Аннан соң экранда транспорт чаралары сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтелә. Балалар бирелгән рәсемнәрдән артык транспорт чарасын сайлап алалар һәм аларның кайсы төргә туры килүен аңлаталар. Ялгыш җавап биргән бала уеннан чыгып бара.



***«Светофор» уены***


***Уенның авторы*** – тәрбияче Зарипова Гөлназ Исмәгыйль кызы.

***Бурычлар:*** балаларның сөйләм телен үстерү; төсләр, светофор сигналлары турындагы белемнәре ныгыту.

***Материал:*** төсләр сурәтләнгән карточкалар, светофор макеты, проектор.

***Уен барышы.*** Балалар үзләренә өләшкән төрле төстәге карточкаларның төсләрен әйтәләр. Төсләрне кабатлагач, экранда светофор рәсеме һәм төрле төстәге түгәрәкләр күрсәтелә. Тәрбияче балалар белән све-

тофорның нәрсә икәнен, нинди вазыйфа башкаруын, нинди сигналлары барлыгын сораулар ярдәмендә тикшерә. Светофор турында тулы мәгълүмат алгач, балалар экрандагы бирелгән төсләрдән светофор сигналындагы төсләрне сайлап куярга тиеш.




***«Серле фигуралар» уены***

***Уенның авторы*** – тәрбияче Зарипова Гөлназ Исмәгыйль кызы.

***Бурычлар:*** балаларның юл хәрәкәте кагыйдәләренә кагылышлы терминнар турындагы белемнәрен ныгыту, геометрик фигураларны кабатлау.

***Материал:*** геометрик фигураларның макетлары, проектор.

***Уен барышы.*** Балалар алдына ике тартма куела. Беренче тартмада геометрик фигуралар төшерелгән карточкалар, икенче тартмада юл хәрәкәте кагыйдәләре терминнарына кагылышлы карточкалар. Уен башында тәрбияче балалар белән геометрик фигураларны кабатлый, аннан соң карточкалар ярдәмендә юл хәрәкәте кагыйдәләренә кагылышлы терминнар турындагы белемнәрен тикшерә. Экранда геометрик фигуралар сурәтләнгән слайд күрсәтелә. Һәр фигура артында юл хәрәкәте кагыйдәләре терминнарына кагылышлы рәсемнәр «яшерелгән», балалар аларның аталамаларын әйтергә һәм бу рәсемнәрнең юлда йөргәндә нәрсә өчен кирәк булуын аңлатырга тиешләр.



***«Шаян фигуралар» уены***

***Уенның авторы*** **–** тәрбияче Зарипова Гөлназ Исмәгыйль кызы.

***Бурычлар:*** балаларның транспорт чаралары һәм геометрик фигуралар турындагы белемнәрен киңәйтү, санау тәртибен искә төшерү.

***Материал:*** проектор, компьютер, уенчык автомобильләр.

***Уен барышы.*** Балаларга экранда транспорт чаралары рәсемнәре күрсәтелә. Аларга төрле геометрик фигуралар «төялгән». Балалар ике командага бүленә. Беренче команда транспорт чараларын атый һәм аларның


кайсы төргә туры килүен аңлата. Икенче команда транспорт чараларына төялгән геометрик фигураларның исемен әйтә һәм аларны санап күрсәтә. Уен барышында тәрбияче балаларга сораулар бирә:

-Экранда кайсы транспорт чарасы сурәтләнгән?

- Әлеге транспорт чарасына нәрсәләр төялгән?

- Транспорт чарасында ничә геометрик фигура бар?

Күбрәк дөрес җавап биргән команда җиңүче була.



***«Велосипед йөртүчене дөрес итеп киендер» уены***

***Уенның автор*** – тәрбияче Вәлиева Гөлнара Зәнфир кызы.

***Бурычлар:*** балаларга велосипед йөртүченең махсус киеме барлыгы хакында мәгълүмат бирү. Әлеге киемнәр велосипед йөртүченең гомерен һәм сәламәтлеген сакларга ярдәм итүен аңлату.

***Материал:*** проектор, компьютер, төрле предметлар төшерелгән карточкалар.

***Уен барышы.*** Балалар белән велосипед һәм велосипедта йөргәндә үз иминлеген саклау кагыйдәләре хакында әңгәмә үткәрелә. Бирелгән мәгълүматны ныгыту өчен, велосипед йөртүче һәм аның махсус киемнәре сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтелә. Рәсемнәрдә артык киемнәр дә бар. Балалар бирелгән рәсемнәрдән велосипедчының киемнәрен дөрес итеп сайлап алырга тиеш. Уенны балаларны берничә командага бүлеп тә үткәрергә мөмкин. Иң күп дөрес җавап биргән команда җиңүче була.



**«Дөресме, ялгышмы?» уены**


***Уенның авторы*** – тәрбияче Зарипова Гөлназ Исмәгыйль кызы.

***Бурычлар:*** балаларның игътибарлылыкларын, сөйләм телләрен үстерү, юл хәрәкәте кагыйдәләре турындагы белемнәрен ныгыту.

***Материал:*** төрле юл йөрү кагыйдәләре сурәтләнгән карточкалар.

***Уен барышы.*** Балалар ике командага бүленә. Һәрбер командага юл йөрү кагыйдәләренә кагылышлы хәлләр төшерелгән карточкалар өләшенә. Балалар шушы карточкаларга карап, әлеге хәлләр юл йөрү кагыйдәләре буенча дөреслекккә туры килүен яки ялгыш булуын аңлатып бирергә тиешләр. Кайсы команда күбрәк дөрес һәм тулы җаваплар бирә, шул команда җиңүче була.





### ***«Сөйләүче юл билгеләре» уены***

***Уенның авторы*** – тәрбияче Вәлиева Гөлнара Зәнфир кызы.

***Бурычлар:*** балаларның образлы фикерләү сәләтен, юл билгеләре турындагы белемнәрен, игътибарлылыкларын үстерү.

***Материал:*** юл билгеләре төшерелгән рәсемнәр яки проектор һәм ноутбук.

***Уен барышы.*** Балаларга юл билгеләре төшерелгән карточкалар өләшенә. Балалар һәр юл билгесенең нәрсә аңлатканын әйтеп бирергә тиеш. Әлеге уенны проектор ярдәмендә дә үткәрергә була. Экранга юл билгеләре рәсемнәре чыга, балалар аларның мәгънәсен аңлатып барырга тиеш булалар.




**«Юл билгеләре» уены**

***Уенның авторы*** – тәрбияче Зарипова Гөлназ Исмәгыйль кызы.

***Бурычлар:*** балаларның юл билгеләре турындагы белемнәрен киңәйтү, сөйләм телен үстерү.

***Материал:*** юл билгеләренең макетлары, проектор.

***Уен барышы.*** Уен башында балаларга юл билгеләре төшерелгән макетлар һәм карточкалар бирелә. Тәрбияче һәм балалар барлык юл билгеләренең нәрсә аңлатуын һәм кешегә ни өчен кирәклеген кабатлыйлар. Экранда юл билгеләре сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтелә, ләкин бу рәсемнәр тулы түгел. Балаларга рәсем кисәкләреннән тулы һәм дөрес булган юл билгеләрен җыярга, әлеге билгеләр нәрсә аңлатканын әйтергә кирәк. Бөтен юл билгеләрен дә дөрес җыйган бала уенның җиңүчесе була.


OP
ST

## Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә юлларда тормыш иминлеге кагыйдәләрен өйрәтү өчен уеннар (5 – 7 яшьлек балалар өчен)

### *«Сүзне укы!» уены*


***Уенның авторы*** – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.

***Бурычлар:*** балаларның юл хәрәкәте кагыйдәләре турындагы белемнәрен ныгыту, игътибарлылыкларын, уку күнекмәләрен үстерү.


***Материал:*** бирем язылган кәгазьләр һәм рәсемнәр.

***Уен барышы.*** Балаларга бирем язылган кәгазьләр һәм шушы биремнең җавабы сурәтләнгән рәсемнәр таратыла. Балалар, уклар белән күрсәтелгән юнәлеш буенча, хәрефләрдән сүзләр төзи, сүз аңлаткан предметның рәсемен таба һәм аның нинди вазыйфа үтәгәнен аңлата.

№1




№2



***«Сихерләнгән сүзләр» уены***


***Уенның авторы*** – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.

***Бурычлар:*** балаларның игътибарлылыгын, тиз фикер йөртә белү сәләтен үстерү.

***Материал:*** уен өчен кирәкле таблицалар ясалган кәгазьләр.

***Уен барышы.*** Балаларга таблицалар ясалган кәгазьләр бирелә. Таблицаларда китерелгән билгеләр буенча буш шакмакларны хәрефләр белән тутырырга, мәкальне укырга һәм мәгънәсен аңлатырга кирәк.

Уенны берничә командага бүленеп тә үткәрергә мөмкин. Мәкальне хатасыз укыган һәм мәгънәсен дөрес итеп аңлаткан команда җиңүче була.





***«Һәр хәрефнең яңа "өен" тап!» уены***

***Уенның авторы*** – тәрбияче  Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.

***Бурычлар:*** балаларның юл хәрәкәте терминнары турында белемнәрен ныгыту, игътибарлылыкларын, тиз фикер йөртә белү сәләтләрен үстерү, уку күнекмәләрен камилләштерү.

***Материал:*** таблица ясалган кәгазьләр.

***Уен барышы.*** Педагог балаларны ике командага бүлә һәм шакмакларга хәрефләр язылган кәгазьләр тарата. Хәрефләрне алар урнашкан шакмактан чыккан уклар буенча барып, дөрес эзлеклелектә урнаштырырга кирәк. Бирем дөрес үтәлгән очракта, шакмакларда юл хәрәкәтенә кагылышлы терминнар килеп чыга. Командалар үзләре тапкан терминны сүзсез генә, пантомима ярдәмендә, каршы як командага аңлатырга тиеш булалар.



***«Яшерелгән сүзләр» уены***

***Уенның авторы*** – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.


***Бурычлар:*** балаларның сүзлек запасын юл хәрәкәтенә кагылышлы терминнар белән баету, игътибарлылыкларын үстерү, уку күнекмәләрен ныгыту.

***Материал:*** таблица ясалган битләр.

***Уен барышы.*** Балалар бирелгән таблицадан юл хәрәкәтенә кагылышлы сүзләрне табып укырга тиешләр.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| К | С | Т | Ж | Ч | Д | Р | У | Л | Ь |
| М | Т | Б | Ю | Л | Ф | К | Ш | З | Х |
| Д | Б | О | Г | П | Ң | Т | Д | Э | Е |
| П | Г | Р | Х | Ж | Е | З | Л | О | Ъ |
| О | Р | З | У | Ө | В | Ф | Ч | Я | Ы |
| Л | С | В | Е | Т | О | Ф | О | Р | Й |
| З | Р | Э | Е | У | К | Ү | П | Е | Р |
| М | Е | Т | Р | О | Ы | Л | Э | Х | З |
| С | И | Ь | Ш | Г | И | К | У | Ц | В |
| Ы | Ф | Й | З | Е | Б | Р | А | Щ | Х |
| Т | Р | О | Т | У | А | Р | С | Б | Ю |

**Кроссворд «Транспорт чаралары»**
**Авторы – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы**





Вертикаль буенча «Транспорт» сүзе билгеле. Кроссвордны чишәргә, горизонталь һәм вертикаль буенча бирелгән шакмакларга сүзләрне язарга кирәк.

Горизонталь буенча сораулар:

1. Җәяүлеләр маршрут транспорт чарасын көтә торган махсус урын ничек атала? (Тукталыш)
2. Йөртүче тәгәрмәчләрне нәрсә ярдәмендә бора? (Руль)
3. Светофорның әзерләнергә куша торган сигналы нинди төстә? (Сары)
4. Транспорт чарасы өчен ягулык. (Бензин)
5. Ике тәгәрмәчле транспорт чарасы. (Велосипед)
6. Уф-пуф сулар,
Уфтанса да алып китәр,
Барыр җиреңә җитәр. (Поезд)
7. Авызы юк, борыны юк,
Тик бар аның өч күзе.
Урамдагы хәрәкәтне
Көйләп торадыр үзе. (Светофор)
8. Елга аркылы чыгу өчен корылма. (Күпер)
9. Юлның җәяүлеләр йөри торган өлеше. (Тротуар)

**Кроссворд «Светофор»**
**Авторы – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы**




Кроссвордны чишәргә, вертикаль һәм горизонталь буенча бирелгән шакмакларга сүзләрне язарга.

Вертикаль буенча сораулар:

1. Селкенми дә, кычкырмый да,
Тыныч кына тик тора.
Автомобиль һәм кешеләрне
Дөрес юлга җибәрә. (Светофор)

Горизонталь буенча сораулар:

2. Тәгәрмәчле транспорт чарасы хәрәкәтләнүе өчен каты өслек белән капланган юл. (Шоссе)
3. Маршрутлы транспорт чарасы. (Автобус)
4. Юл хәрәкәтен көйләүченең сырлы таягы. (Жезл)
5. Җир асты транспорт чарасы. (Метро)
6. Ике тәгәрмәчле моторлы транспорт чарасы. (Мопед)
7. Юлның өске каты катламы. (Асфальт)
8. Автомобиль маркасы. (Ока)
9. Автобус маркасы. (Икарус)

***«Автомобильләрнең маркалары» уены***

***Уенның авторы*** – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.

***Бурычлар:*** балаларның автомобильләрнең маркаларын таный алуларына ирешү, фикерләү сәләтләрен, сүзгә аваз анализы ясау күнекмәләрен үстерү.

***Материал:*** проектор, ноутбук.

***Уен барышы.*** Экранда күрсәтелгән рәсемнәрдәге предмет атамаларының беренче авазын ачыкларга һәм алардан сүз төзергә кирәк. Биремне дөрес эшләгән очракта, автомобиль маркасы атамасы килеп чыга.




### *«Юлдан барабыз» уены*

***Уенның авторы*** – укытучы-логопед Баһаветдинова Илсөя Зөфәр кызы.

***Бурычлар:*** балаларның юл билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту, сөйләм сулышын үстерү. Р, Ш, С, Л авазларын ныгыту.

***Материал:*** автомобиль, светофор, автомобиль үтәсе юл сурәтләнгән рәсем.

***Уен барышы:*** балалар, рәсемгә карап, авазларны дөрес итеп сузалар, кирәк юл хәрәкәтләрендә туктап торалар.



### *«Кайсы артык?» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.

***Бурычлар:*** төркемли белү күнекмәләрен, гомумиләштерүче сүзләрне һәм логик фикерләүне, сүз байлыгын, игътибарлылыкны үстерү.

***Материал:*** проектор, ноутбук.

***Уен барышы.*** Артык транспорт чарасын табарга һәм аның ни өчен артык булуын аңлатырга.




*«Нәрсә яшерелгән?» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.

***Бурычлар:*** балаларның игътибарлылыгын үстерү, хәтер күләмен арттыру.

***Материал:*** проектор, ноутбук.

***Уен барышы.*** Балалар рәсемгә карыйлар һәм нинди сүрәтләр яшерелгәнен әйтәләр.




### *«Охшаган, охшамаган?» уены*

***Уенның авторы*** **–** тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.

***Бурычлар:*** балаларның игътибарлылыгын үстерү, юл билгеләре турында белемнәрен ныгыту.

***Материал:*** юл билгеләре төшерелгән рәсемнәр.

***Уен барышы.*** Педагог балалар белән бергә юл билгеләре төшерелгән рәсемнәрне карый, аларның төсләренә, формаларына игътибар иттерә. Педагог балаларны берничә командага бүлә һәм түбәндә китерелгән юл билгеләренең охшаш һәм аермалы якларын тасвирларга куша. Иң күп дөрес җавап биргән команда җиңүче дип билгеләнелә.




### *«Нәрсә югалды?» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.

***Бурычлар:*** балаларның игътибарлылыгын, хәтер күләмен, тиз фикер йөртү сәләтләрен үстерү.

***Материал:*** проектор, ноутбук.

***Уен барышы.*** Балалар берничә секунд юл билгеләренә карап торалар һәм аннары күзләрен каплыйлар. Бу арада юл билгесенең берсе югала. Балалар кайсы юл билгесе югалганын белергә һәм аның нинди вазыйфа үтәгәнен аңлатырга тиеш.




### *«Нинди билге?» уены*

***Уенның авторы*** – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.

***Бурычлар:*** балаларның юл билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту; тиз фикер йөртә белү сәләтләрен, ситуацияне аңлап, фикерләрен башкаларга дөрес итеп җиткерә белү күнекмәләрен үстерү.

***Материал:*** проектор, ноутбук.

***Уен барышы.*** Балалар рәсемгә карап, юлның бу өлешендә нинди юл билгесе булырга тиешлеген аңлаталар.




***«Хатаны тап» уены***

***Уенның авторы*** – тәрбияче Шәрәфиева Лилия Фаиз кызы.

***Бурычлар:*** сөйләмнәрен үстерү; балаларның юлда иминлек кагыйдәләрен үтәү турындагы белемнәрен ныгыту, юлдагы ситуацияне дөрес бәяли белергә өйрәтү.

***Материал:*** проектор, ноутбук.

***Уен барышы.*** Балалар, рәсемгә карап, юлдагы ситуацияне ачыклыйлар, ялгыш очракларны күрсәтәләр, аңлатма бирәләр.



## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Айсина, Р.М. «Организация работы отрядов юных инспекторов движения (ЮИД)» (18 часов) дополнительная профессиональная образовательная программа курсов повышения квалификации педагогических работников дошкольных образовательных организаций / Р.М. Айсина [Электронный ресурс]. – Режим доступа: http://минобрнауки.рф/документы/4963 (03.12.2018).

2. Асянова, С.Р. Формирование безопасного поведения школьников на дорогах в условиях современного города [Текст]: автореф. дис. ... канд. пед. наук / Светлана Рифовна Асянова; Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы. – Уфа, 2012. – 23 с.

3. Ахмадиева, Р.Ш. Теоретические основы формирования безопасности жизнедеятельности на дорогах как компетенции участника дорожного движения [Текст] / Р.Ш. Ахмадиева // Вестник Казанского государственного технического университета им. А.Н. Туполева. – 2011. – №2. – С. 175–178.

4. Ахмадиева, Р.Ш. Формирование личностной компетенции участника дорожного движения [Текст] / Р.Ш. Ахмадиева // Казанский педагогический журнал. – 2010. – №5-6. – С. 11–18.

5. Ахмадиева, Р.Ш. Концептуальные основы формирования личностной компетенции участника дорожного движения [Текст] / Р.Ш. Ахмадиева // Известия Казанского государственного архитектурно-строительного университета. – 2011. – №2 (16). – С. 335–340.

6. Ахмадиева, Р.Ш. Обучение участников дорожного движения правилам безопасного поведения на дороге на основе компетентностного подхода [Текст] / Р.Ш. Ахмадиева // Ученые записки Казанского университета. Серия: Гуманитарные науки. – 2011. – Т. 153. – №5. – С. 136–142.

7. Ахмадиева, Р.Ш. Формирование компетенции безопасности жизнедеятельности на дорогах на основе принципа непрерывности [Текст] / Р.Ш. Ахмадиева // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. – 2011. – №2. – С. 44–47.

8. Бабич, А.А. Технология мониторинга региональных систем непрерывного обучения детей безопасному участию в дорожном движении и профилактики детского дорожно-транспортного травматизма [Текст] / А.А. Бабич // Сб. материалов II Ежегодной конференции Северо-Кавказского федерального университета «Университетская наука – региону». – Ставрополь: Фабула, 2015. – С. 134–137.

9. Бабич, А.Г. Теоретико-методические подходы к проведению мониторинга региональных систем непрерывного обучения детей дорожной безопасности [Текст] / А.Г. Бабич, Р.Г. Тер-Григорьянц; Министерство образования и науки РФ, Сев.-Кавк. федер. ун-т, Науч.-метод. центр образования, воспитания и социал. защиты детей и молодежи «СУВАГ». - Ставрополь: Ставролит, 2016. – 135 с.: ил.

10. Беженцев, А.А. Безопасность дорожного движения: учебное пособие [Текст] / А.А. Беженцев. – М.: Вузовский учебник, 2017. – 272 с.

11. Безопасность и развитие личности в образовании [Текст] / Материалы Всероссийской научно-практической конференции; 15-17 мая 2014 г. – Таганрог: Изд-во ЮФУ, 2014. – 371 с.

12. Белугин, М.Г. Структурно-функциональная модель организационно-педагогического сопровождения обеспечения безопасности дорожного движения школьников [Текст] / М.Г. Белугин // Казанский педагогический журнал. – 2014. – №6 (107). – С. 65–74.

13. Белугин, М.Г. Педагогические условия организационно-педагогического сопровождения обеспечения безопасности дорожного движения школьников [Текст] / М.Г. Белугин, Р.Ш. Ахмадиева // Проблемы современного педагогического образования. – 2016. – №52-6. – С. 8–19.

14. Блинкин, М. Я. Безопасность дорожного движения: история вопроса, международный опыт, базовые институции [Текст] / М. Я. Блинкин, Е.М. Решетова. – М.: Изд. Высшая школа экономики, 2013. – 240 с.

15. Гордиенко, С.А. Азбука дорожного движения для детей и для родителей, для пешеходов и водителей [Текст] / С.А. Гордиенко. – Ростов-н/Д: Феникс-Премьер, 2015. – 64 с.

16. Добрая дорога детства: интернет портал [Электронный ресурс]. – Режим доступа: http://www.dddgazeta.ru/ (03.12.2018).

17. Елжова, Н.В. ПДД в детском саду: развивающая среда и методика по ознакомлению детей с ПДД, перспективное планирование, конспекты занятий [Текст] / Н.В. Елжова. – Ростов-н/Д: Феникс, 2014. – 170 с.

18. Забуслаева, О.Н. Использование проектной деятельности в процессе формирования основ культуры безопасности ПДД у детей среднего дошкольного возраста [Текст] / О.Н. Забуслаева, М.Н. Малкова, М.О. Смолянинова // Образовательная среда сегодня: стратегии развития. - 2016. – №1 (5). – С. 64–69.

19. Игнатова, С.В. Учим Правила дорожного движения: наглядно-методический комплект для дошкольников и младших школьников [Текст] / С.В. Игнатова. – М.: Ювента, 2013. – 80 с.

20. Куленева, О.В. Методика проведения мониторинга уровня сформированности готовности детей дошкольного возраста к соблюдению правил безопасного поведения на дорогах: методические рекомендации [Текст] / О.В. Куленева, Г. Х. Насрутдинова, Е. А. Ярусова. – Казань: ООО «Фолиант», 2015. – 40 с.

21. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юлларда үзләрен хәвефсез тоту кагыйдәйләренз өйрәтү дәресләре циклы: методик күрсәтмәләр [Текст] / Авт.-төз.: Г.А. Галеева, С.М. Гаффарова, З.Л. Ишниязова, Р.Ш. Ахмадиева һ. б. – Казан: «Балаларның тормыш иминлеге фәнни үзәге» ДУ нәшрияты, 2010. – 236 б.

22. Обучение детей в дошкольных образовательных организациях правилам безопасного поведения на дорогах. (Вариативный модуль к образовательной области «Социально-коммуникативное развитие»): учебно-методическое пособие для педагогов дошкольных образовательных организаций [Текст] / Р.Ш. Ахмадиева, Н.С. Аникина, Е.Е. Воронина, В.Н. Попов; Под общей ред. Р.Ш. Ахмадиевой. – Казань: ГБУ «НЦБЖД», 2016. – 100 с.

23. Обучение детей безопасному поведению на дорогах: методические рекомендации для работы с родителями [Текст] / Р.Ш. Ахмадиева, М.Г. Белугин, М.Х. Валиев, Е.Е. Воронина / Под общей ред. Р.Ш. Ахмадиева. – Казань: ГБУ «НЦБЖД», 2014. – 112 с.

24. Обучение детей дошкольного возраста правилам безопасного поведения на дорогах: учебное пособие [Текст] / Авт.-сост.: Р.Ш. Ахмадиева, Е.Е. Воронина и др.; Под общей ред. Р.Н. Минниханова и Д.М. Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦБЖД», 2008. – 324 с.

25. Русско-татарский-английский словарь по безопасности дорожного движения [Текст] / Р. Ш. Ахмадиева, М. Х. Валиев, Р.А. Даутова, М.В. Кильдеев и др.; Под общей ред. Р.Ш. Ахмадиевой, Р. Н. Минниханова. – Казань: Артефакт, 2014. – 168 с.

26. Саулина, Т.Ф. Знакомим дошкольников с правилами дорожного движения: для занятий с детьми 3-7 лет. ФГОС [Текст] / Т.Ф. Саулина. – М.: Мозаика-Синтез, 2014. – 112 с.

27. Цикл занятий для детей дошкольного возраста по обучению правилам безопасного поведения на дорогах: сборник конспектов занятий [Текст] / Сост.: Г.А. Галеева, С.М. Гаффарова, З.Л. Ишниязова, Р.Ш. Ахмадиева и др.; Под общей ред. Д.М. Мустафина. – Казань: ГУ «НЦ БЖД», 2009. – 240 с.

Методик тәкъдимнәр җыентыгы

# Уйный-уйный өйрәнәбез

Мәрданова Айгөл Әбделганиевна,
Таипова Гөлназ Камилевна,
Зарипова Гөлназ Исмәгыйлевна,
Вәлиева Гөлнара Зәнфировна,
Шәрәфиева Лилия Фаизовна,
Баһаветдинова Илсөя Зөфәровна

Рәссам Щетинкина Ю.А.
Компьютерда бизәлеш: Прыганова В.В.
Редактор: Кадирова Э.Х.

«Тормыш иминлеге фәнни үзәге»
дәүләт бюджет учреждениесе нәшрияты
420059 Казан шәһәре, Оренбург тракты ур., 5.
Басарга кул куелды . Шартлы басма табак .
Офсет басмасы.

Формат 60×90/16. Тираж 10 000 данә.
Отпечатано ООО «Фолиант»